| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Салаушского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Салагыш авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 07.02.2020 | Салагыш авылы | № 58-1 |

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Салагыш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының 2020 елның 20 гыйнварыннан 02-08-01/35 номерлы «Салагыш авыл җирлеге Уставының аерым нигезләмәләренә карата протесты»н үтәү йөзеннән, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Салагыш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советы **К А Р А Р И Т Т Е:**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын беренче укылышта кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча; Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Түбәндәге составта карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

Мөхәмәдиев М.М. – Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советы Рәисе, Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге башлыгы;

Халматов Р.С.– Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге депутаты;

Шайхутдинов А.Н. – Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл

җирлеге депутаты;

Самигуллин И.М. – Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге депутаты;

Сахипов И.И. – Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге депутаты.

4. Әлеге карарның ачык тыңлауларын 2020 елның 17 февралендә сәгать 10:00да Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Салагыш авыл клубы бинасында үткәрергә.

5. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына карата Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советы депутатлары һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге Советына карауга чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы М.М. Мөхәмәдиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Салагыш авыл җирлеге Советының
07.02.2020 № 58-1
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты**

**29нчы статьяның 7нче өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар хокуклы түгел:

«1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) түләүсез катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән түләүсез идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш), Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиле рөхсәте белән катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән, муниципаль хокукый актлар яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибе нигезендә муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (акционер, анда катнашучы), оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә, муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен яклау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар,

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит

ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) идарә органнары, попечительлек яки күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса.

7.1. Гражданин контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр, муниципаль берәмлек башлыгы белән якын туганлык яки туганлык (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абыйлы-энеле, апалы-сеңелле, шулай ук ире-хатынының бертуганнары, апа-сеңелләре, ата-аналары, балалар) очрагында, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын били алмый.».